**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

16 январь 2019 ел №128

**Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Дәвеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Дәвеш авыл җирлеге Советының 2016 ел, 12 февраль 17 нче номерлы карары белән расланган “Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле 5.5.1 статья өстәргә:

«5.5.1. җирлек башлыгы, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта яки үзлектә (ата-анасы, хатыны, балалары, бертуган абый-энеләре, сеңелләре, шулай ук ире яисә хатынынын бертуган абый-энеләре, сеңелләре, ата-аналары, балалары, балаларынын хатыны яисә ире) булган очракта, гражданин муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы Рәисе, Рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгелэнэ алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы Рәисе, Рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасын били алмый.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Дәвеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Дәвеш авыл җирлеге башлыгы Т.Т.Хөсәенов**